КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 октябрь г.Казань № 906

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 976 нчы; 2016 ел, 22 декабрь, 969 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен;

Татарстан Республикасының рекреацион зонасы паспорты формасын.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибендә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын, паркларны, скверларны (бульварларны) да кертеп, карап тотуга һәм ремонтлауга финанс чыгымнары күләмнәрен исәпләү муниципаль берәмлекләр киселешендә тышкы төзекләндерү объектларының техник паспортлары һәм (яки) тышкы

төзекләндерү объектларының техник планнары, шулай ук рекреацион зоналар (парклар, скверлар (бульварлар) паспортлары белән расланган характеристикалары нигезендә гамәлгә ашырыла, алар актуаль халәттә формалаша һәм хуплана.»;

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен проектлаштыру буенча республика нормативларын раслау турында» 2013 ел, 27 декабрь, 1071 нче карары»;

әлеге карарга Татарстан Республикасы рекреационной зоны паспорты формасын өстәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин